# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 14 (666) 26 июль 2018 ел (1439, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Болгар җыены



Бабаларыбыз Ислам динен рәсми кабул иткән көнгә багышланган Болгар җыены быел 29 нчы мәртәбә үткәрелде. Аны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ачты. Мөселман кардәшләребезне ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин котлады.

"Изге Болгар җыенын үткәрү Идел буе-Урал төбәге мөселман халыкларының күркәм традициясенә әверелде. Әлеге чара ел саен меңләгән мөселман кардәшләребезне Россиядә Исламның меңъеллык тарихы белән танышырга Татарстанга җыя, – диде мөфти үз чыгышында. – Болгар җыены әлбәттә, халкыбыз өчен мөһим вакыйга, бу очрашу безнең тамырларыбызга, мәдәниятебезгә һәм тарихыбызга якынаерга ярдәм итә. Билгеле ки, үзенең үткәнен белмәгән һәм хөрмәт итмәгән халыкның киләчәге дә юк".

Кунакларны Русия Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Чечня Республикасы мөфтие Сәлах хаҗи Межиев һәм башкалар сәламләде.

Быелгы җыен барышында яңа өч объект ачылды. Аның беренчесе – Болгар чәй эчү музей экспозициясе. Ул чәй эчү традициясен яктырта. Биредә Спас районында үстерелгән чәй үләннәрен алу мөмкинлеге дә бар. Икенче экспозиция "Су өстендәге шәһәр" – "Город на реке" дип атала. Әлеге экспозиция шушы район тарихына бәйле рәвештә оештырылган. Өченче экспозиция Абдулла Алишка багышланган. Белгәнебезчә, күренекле язучы, җәлилче-шагыйрь Спас районында туган. Әлеге музей экспозициясе Назаров урамындагы 19 гасыр йортында урнаштырылган.

Чараны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан мәдәният министрлыгы оештырды.

## Җәмигъ мәчете һәрчак күз уңында

Чаллы шәһәре мэриясендә Җәмигъ мәчете төзелеше буенча чираттагы пресс-конференция узды. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин һәм Җәмигъ мәчете төзелешенә финанс ярдәме күрсәтү фонды җитәкчесе Уел Галим улы Хөсәенов үзләренең чыгышларында 2017 ел эчендә күпме эш эшләнгәнлеге һәм финанс ягыннан керем-чыгым турында мәгълүмат җиткерделәр. Шушы көнгә кадәр, узган елларны да кушып, якынча 45 миллион сумлык эш башкарылган.

Шәһәр өчен бу мәчетнең әһәмияте зур. Чөнки җомга һәм бәйрәм көннәрендә, кайбер мәчетләребездә урын җитмәү сәбәпле, кешеләр намазны урамда укырга мәҗбүр. Шуңа күрә Чаллы халкына Җәмигъ мәчетенең төзелеп бетүе бик мөһим.

## Яшьләр эшли дә, ял да итә



Чаллы шәһәре мөселманнары велосипедта табигатькә ял итәргә чыкты. Очрашу урыны итеп Нур-Ихлас мәчете сайланган иде. Маршрут урман эченнән узды. Барып-кайту арасы 30-35 чакрым чамасы булып чыкты. Тукталыш урыны вазыйфасын дамбада урнашкан култык башкарды. Сәяхәт барлыгы 3-4 сәгать дәвам итте. Чарада Чаллы шәһәренең Нур-Ихлас, ГЭС мәхәлләсе, Утыз Имәни, Әбүзәр һәм башка мәчетләренә йөрүчеләр катнашты. Тукталыш вакытында телгәннәр су керә һәм тамак ялгый алды. Шундый ук җәмәгать белән өйлә намазы да укылды.

Бу чарада, юлның озын булуы аркасында, 16 яшьтән өлкән булганнар гына катнашты. Һәрбер велосипедчы үзен тәртипле тотты, артыннан чүп-чар калдырмады. Катнашучылар, оештыручыларга рәхмәт белдереп, табигать матурлыгына сокланып кайтып киттеләр.

**Нияз Газизов.**

## Тиздән – хаҗ сәфәре

2018 елның 4 августында Казаннан Татарстан хаҗиларының беренче төркеме хаҗга юл тотачак. Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗ кылу өчен 49 кеше китәчәк. 2018 елда Россия мөселманнары өчен барлыгы 20500 кешелек квота бүлеп бирелде. Шул исәптән Татарстан Республикасы өчен – 1800 урын.

"ДУМ РТ Хаҗ"дан Согуд Гарәбстанына юлламаның иң очсыз бәясе 149000 сум тәшкил итә – ул хаҗилар арасында иң популяр пакет.

"ДУМ РТ Хаҗ" өчен хаҗны оештырганда иң мөһиме булып хаҗиларның иминлеген кайгырту һәм алар тарафыннан гыйбадәтләрне хәнәфи мәзһәбе буенча оештыруны тәэмин итү тора. 2018 елда хаҗилар төркеме белән төрле категория һәм белгечлеккә ия 20 табиб йөриячәк. Мина үзәненә медицина хезмәте күрсәтү палаткасы куелачак, ул тиешле медицина җиһазлары һәм медикаментлар белән тәэмин ителәчәк.

Татарстан Республикасы – Россиядә хаҗиларны хаҗ кылырга хәнәфи мәзһәбе нигезләре буенча әзерләүче бердәнбер төбәк. Хаҗ гамәлләрен үтәүгә кагылышлы сорауларга төркем җитәкчеләре җавап бирәчәк.

Татарстанлылар өчен быелгы хаҗ сезоны яңалыгы булып ашау-эчүне оештыру тора – хаҗиларга татар милли ашларын әзерләү өчен пешекче барачак.

## Фестиваль башланды



ТР мөселманнарының Диния нәзарәтендә VI Мөселман яшьләре фестивале ачылды. Быел Болгарда 22-29 июль көннәрендә үтәчәк VI мөселман яшьләре форумында Татарстан, Мари Эл, Чувашия, Удмуртия, Башкортстан, Оренбург, Әстерхан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе, Свердловск өлкәсе, Самара, Саратов, Чиләбе, Төмән, Подольск, Көньяк Сахалиннан 18 яшьтән алып 35 яшькәчә булган яшь мөселманнар катнаша.

## Яңа мәчет

Балык Бистәсе районы Яңавыл авылында мәчет төзелде. "Әхмәдсафа" мәчетенең тантаналы ачылышында күренекле дин әһелләре, Яңавыл һәм күрше авыл җирлекләреннән килгән вәкилләр катнашты.



# Ике юл

**Аллаһы Сүбхәнә Тәгаләнең законнарын без танырга да мөмкин, тәкәбберләнеп китеп, танымаска да мөмкинбез. Ләкин без аларны танысак та, танымасак та, ул законнар эшли. Аллаһы Тәгалә үзенең законнарын урнаштырган һәм үзенең иксез-чиксез кодрәте белән аларның үтәлүен дә булдыра.**

Без бу законнарны аңлап, танып яшәргә мөмкин. Яисә без аларны кабул итмичә, "алай инде ул дөрес түгел, болай итсәк инде артыгын кылану була", дип тә яшәргә мөмкин.

Фәрештәләрнең акылы бар, ихтыяры юк. Алардан соралмаячак. Хайваннарның ихтыяры бар, акылы юк. Алардан да соралмаячак. Кешегә Аллаһы Тәгалә ихтыяр да биргән, акыл да биргән. Кеше үз юлын үзе сайлый. Ләкин нинди генә юлны сайламасын, аның ахырында һәр кешене Аллаһы Тәгалә көтеп тора. Һәр кеше кайтарылыр Аллаһы Тәгалә хозурына һәм һәр кеше сайлаган юлы өчен җавап бирер Аллаһы Тәгалә алдында.

***"Ул – Аллаһ сезгә җирне йөрергә уңай кылды, ул җирнең җилкәсендә йөрегез, теләгән җирендә яшәгез һәм ул җирнең хәләл ризыкларын ашагыз, һәм үлгәннән соң терелеп бармак Аллаһу хозурынадыр." Коръән 67:15.***

Коръәндә, Аллаһы Тәгаләне күрмичә дә, Аңарга иман китерүгә чакырыла, чөнки без Аллаһы Тәгаләне бу дөньяда күрә алмыйбыз. Күргәч инде кем дә Аңа иман китерергә әзер булыр, ләкин инде соң була. Аллаһы Тәгаләнең безне һәр мизгелдә күреп торганына, һәр кылган гамәлебезне белеп торганына без болай да ышанырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә кешегә шундый күп тыюлар куйган дип уйларга була. Ләкин Аллаһы Тәгалә кешегә кыенлык теләми. Кешегә фәкатъ тормышта иң җиңел һәм иң хәерле рәвештә яшәү юлын күрсәтә.

Аллаһы Тәгалә безне барлыкка китерүче һәм шул сәбәпле безнең өчен нәрсә яхшы, нәрсә яман икәнен Ул гына белүче. Һәм шушы белемне Үзенең пәйгамбәрләре аша кешеләргә җиткерә.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә әйтелгәнчә, безнең ризыгыбыз без туганчы ук Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнеп куела. Ул артмый да, кимеми дә. Кеше үзенең ризыгын хәләл юл белән дә, хәрам юл белән дә табарга мөмкин. Сайлаган юлына карап, ризыкның күләме артмый да, кимеми дә. Ләкин хәләл юл белән тапса, Аллаһы Тәгалә бу бәндәдән разый була, бу дөньяда да үзенең ярдәменнән калдырмый, ахирәттә дә югары дәрәҗәгә күтәрә. Ризыгын хәрам юл белән тапса, ул Аллаһы Тәгаләнең ачуына ирешә.

Бу – Аллаһы Тәгаләнең сынавы. Кеше фәкыйрьлеккә төшсә, кыен хәлдә калса, сабырлык күрсәтерме? Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйча, хәрам юл белән ризык эзләргә керешмәсме? Кеше баеп китсә, Аллаһы Тәгалә аңарга биргән малны, байлыкны нинди юлда тотар? Хәләл юллардамы, яисә, минем мал, нәрсә теләсәм шуны эшлим дип, хәрам юлларда тота башламасмы?

Аллаһы Тәгаләнең барлыгын без кыенлык килсә бик яхшы сизәбез. Һәр кешенең була шундый вакыты – инде беркем дә ярдәм итә алмас кебек. Ләкин без котылабыз, тормыш алга китә. Тик без бу котылуыбыз бары тик Аллаһы Тәгаләдән генә икәнен онытмаска тиешбез.

Һәм безнең өчен иң кыены – Аллаһы Тәгаләнең барлыгын безгә яхшы, рәхәт чакта онытмау. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Аллаһыны исеңдә тот һәм син Аны үз алдында күрерсең. Яхшы вакытта Аллаһыны танырга омтыл, Ул сине кайгы вакытыңда калдырмас".

Дин кешеләргә кыенлык өчен бирелмәгән. Киресенчә, җиңеллек өчен бирелгән.

Бала үсә. Аны урап алган тирә-як куркынычмы? Хатыныбыз урамга чыгып китә – куркынычмы? Берәр әйберебезне кайдадыр онытып калдырдык – табылырмы?... Каян килә бу куркулар? Сәбәбе – тирә-якта Аллаһы Тәгаләдән курыкмый торган кешеләр дә әз түгел. Аллаһы Тәгаләдән курыкмаса, дөньяда кеше эшли алмаслык әшәкелек юк.

Ә инде бөтен кеше Аллаһы Тәгалә куйган законнар нигезендә яшәсә, безнең тормыш күпкә җиңеләер иде.

Кайбер кеше әйтә: "Мин болай да бик яхшы яшәп ятам..." Бу кеше өчен әлеге яхшы дигән тормышы Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән сынау түгел микән? Минем бу колым Мин биргән нигъмәтләргә шөкер итәр микән? Яисә, мин булдырам дип, күкрәк киереп йөрер микән? Ул очракта Аллаһы Тәгалә кешегә бик зур сынаулар да җибәрергә мөмкин. Кеше аңласын өчен, Аллаһы Тәгаләне исенә төшерсен өчен. Без һәрвакыт Аллаһы Тәгаләдән күтәрә алмаслык сынаулар бирмәвен сорарга тиеш.

Байлык та сынау. Ярлылык та сынау. Бик бай кешеләрнең дә ярлылыкта үткәргән вакытлары була. Бу вакытта алар нишлиләр? Аллаһы Тәгаләне гаделсезлектә гаеплиләрме? Ни өчен минем бөтен малымны юк итте, мин бит күпме гыйбадәт кылдым, диләрме? Яисә, Аллаһы Тәгалә алда тагын да яхшысын әзерләп куйгандыр дип ышанып, Аңардан юлларын ачуны сорап, бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә тәвәккәл кылып, эшләрен дәвам итәрләрме? Коръәндә Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылырга кушыла, безнең өчен бу фарыз.

***"Аларның малына кызыкма, бәлки һәрвакыт тере, һич үлми торган Раббыңа тәвәккәл ит, һәм Аны мактап тәсбихләр әйт, бәндәләренең гөнаһларыннан хәбәрдар булырга Аллаһ үзе җитә." Коръән 25:58.***

Күп вакытта без тормышыбызда кыенлыклар булса, сәбәбен кешеләрдән эзлибез: кемдер безгә ярдәм итмәгән, тормышта шундый хәлдә калганбыз... Ләкин Аллаһы Тәгалә теләмәсә, агачтан яфрак та төшми. Безнең кыенлыкларның сәбәбе – Аллаһы Тәгалә белән мөнәсәбәтебез төзек булмауда. Безгә аны йөрәгебез әйтә – без ишетмәмешкә салышабыз. Ничектер икенче юл белән кыенлыклардан чыгарга тырышабыз. Кыенлыклар кабат-кабат киләчәк, без аңлаганчы киләчәк. Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында.

***"Дөреслектә файдалы булган җиңеллек – авырлыктан соң". Коръән 94:5***

Һәрвакыт шулай булган. Һәрвакыт шулай булачак та. Аллаһы Тәгалә һәрвакыт булган, бар, һәм Ул һәрвакыт булачак та. Һәм Аллаһы Тәгаләнең законнары да һәрвакыт үтәлә. Адәм г.с. җәннәттә булып, ялгышлык кылып аннан куылса да, Аллаһы Тәгаләгә ышануын югалтмаган, һәм җирдә тормышын җайлап җибәрә алган. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән! Мөселманнарның элекке замандагы тормышы турында әкиятләрдә дә күрә алабыз: Синдбад ничә тапкыр Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылып, юлга чыгып киткән, нинди генә кыенлыклар һәм югалтуларга очраса да, һәрвакыт тагын да баерак булып туган якларына әйләнеп кайткан.

***" Мине истә тотыгыз – мин дә сезне онытмасмын..." Коръән 2:152.***

Кешеләрдән аермалы буларак, Аллаһы Тәгаләнең таләпләре үзгәрми. Без берәр кешедән ярдәм өмет итсәк, ул кешегә без әле ярый алабызмы, юкмы, кем белә бит. Кеше бик үзгәрүчән. Ә Аллаһы Тәгаләгә генә ышансак, Аңардан гына ярдәм көтсәк, безнең өчен бу бик зур җиңеллек. Аллаһы Тәгалә синнән нәрсә көтә? Беләсең. Ничек дөрес эшләргә? Беләсең. Һәм бу үзгәрми.

Коръәндә, әлбәттә, куркыту да бар. Ләкин аның мәгънәсе нәрсәдә соң? Аллаһы Тәгалә кешеләргә үзенең бердәнбер икәнен аңлатырга тели: әгәр Миннән кала тагын кемгәдер табынасыз икән, ярдәмне Миннән башкалардан көтәсез икән – карагыз. Кыямәт көнендә Минем каршыма килеп баскач, Мин сезне утка атармын – чакырыгыз кемгә сез табындыгыз! Миннән сезне кем саклый алыр?! Бу куркытуның мәгънәсе – Аллаһы Тәгаләгә тиң зат юклыгын кешегә иң гади һәм аңлаешлы рәвештә җиткерү.

Ләкин Коръәндә Аллаһы Тәгалә бик күп тапкыр кабатлый: дөрес юлга басыгыз, гафу итәрмен, ди. Кодси хәдистә Аллаһы Тәгалә әйтә: "Миңа таба бер адым атласагыз, Мин сезгә ун адым атлыйм. Миңа каршы атлап килсәгез, Мин сезгә каршы йөгереп киләм".

Сорау туарга мөмкин: ни өчен Аллаһы Тәгалә кешегә сынаулар бирә соң?.. Ә сынамыйча кайдан беләсең?

***"Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, йөкләмәләр йөкләп сезне сынамак өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белмәк өчен. Ул һәрнәрсәдән өстен һәм ярлыкаучы". Коръән 67:2***

**Илдар хәзрәт Зияров,**
**Чаллы, "Хәләл-Үзәк".**

## СОРАУ-ҖАВАП

Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ җавап бирә.

**Намаз казага калганда, фарызын да, сөннәтен дә уку кирәкме, әллә фарызын гынамы? Икенде намазы беткәнче, казага калган намазны уку дөрес түгел диләр. Рәфыйк хәзрәткә шушы сорауны бирәсем килгән иде.**

**Рамил, Чаллы шәһәре.**

**Җавап:** Казага калган намазларның фарызлары гына каза кылына, сөннәтләр каза кылынмый. Мәгәр иртәнге намаз казага калса, шул ук көнне өйлә вакыты кергәнче каза кылсаң – сөннәтен дә каза кылу тиеш була, өйләдән соң каза кылсаң – фарызы гына каза кылына, башка намазлар кебек. Каза кылуның икенде намазы белән бер бәйләнеше дә юк.

**Ир-атка алтын бизәнү әйберсе кияргә ярамый дигәнне ишеттем, алтын балдак та ярамый микәнни? Яшь чакта өйләнешкәндә кигән балдакны нишләтергә соң?**

**Руслан, Мөслим.**

**Җавап:** Ир кешегә алтын балдак та кию ярамый. Аны хатын-кызларга бирегез, яки сатып җибәрегез.

**Олы кеше булгач, кибеттә вак кына итеп язылган бөтен язуны да укып булмый. Желатин кушылган ризык хәләл түгел, диләр, аны укып-күрмәгәч, каян белергә, нишләргә соң? Бу чын сүзме? Беркөн кибеттә хәләл эремчек, хәләл сыр күреп, аптырадым. Сөт ризыклары арасында харамы да була микәнни?**

**Зөлайха апагыз,**
**Казан шәһәре.**

**Җавап:** Үзегез күрә алмасагыз, кибетчеләрдән сорагыз, алар укып бирерләр яки карап әйтерләр. Желатин чыннан да харам санала, чөнки ул итләрнең сеңер кебек әйберләреннән ясала. Билгеле булганча, мөселманча суелмаган малларның итләре харам була, алардан ясалган желатин да шулай ук харам. Сырларны, эремчекләрне ясар өчен кайбер очракларда малларның ашказанының сычуг дип атала торган өлешеннән ясалган порошокны оеткы итеп сөткә салалар. Шулай ясалган сырлар, эремчекләр харам була. Мәгәр мөселманча суелган малның сычугы кулланылса, хәләл була.

*Безгә язалар*

# Һәр сорауга җавап бар…

Үзебезнең Чаллы татар дәүләт драма театры артисты Гөлсинә Минһаҗеваның “Яратылмаган ярлар” спектаклендәге Илсөяр роле өчен урын алганлыгы турында укыдым. Бу спектакльне гаилә белән караган идек. Баруның сәбәбе шул булды – әбинең сөйләве буенча, аны да, бу спектакльнең герое кебек, 14 яшьтән окоп казырга җибәргәннәр. Тамашаны зал бик игътибар белән карады. Күпләрнең күзендә яшь иде. Спектакльнең соңында Илсөяр шундый сорау салды: ни өчен безнең буынга мондый бәла килде? Җавап тамашачыга калдырылды. Бу сорауга җавап шундый булырга тиеш.

Без, татарлар, үзебезне мөселман дип атыйбыз. Җавапны да динебездән эзләргә кирәк. Хәдис буенча, бу дөньяда яфрак та Аллаһның рөхсәтеннән башка өзелмәс, коелмас. Әлеге сорау, бәла дә Аллаһның рөхсәте белән килгән булырга тиеш. Ни өчен? Дөньядан бер мисал китерсәк, аңлашылыр. Әйтик, сабый бала артык шуклана башласа, аңа әти-әнисе, я укытучы кисәтү ясый. Бармак яныйлар, яки катырак сүз белән тыялар. Нәтиҗә булмаса, йомшак урынына әти-әнисеннән эләгә. Бала шулай сабак ала, моның белән һәркем килешер.

Аллаһының адәм балаларын бу дөньяга китерүенең дә сәбәбе шунда: ул үзен таныттырырга тели, бу дөньяның матурлыклары белән, хикмәтләре белән, нигъмәтләре белән. Шушы нигъмәтләргә шөкер итәргә куша, гыйбадәттә булып, кушканнарын үтәп, тыйганнардан тыелып, тәкъва мөселманнар булуыбызны таләп итә. Һәрнәрсәнең дәрәҗәләре булган кебек, шөкернең дә дәрәҗәләре бар. Безгә балачактан “әппәр” әйтергә кушалар иде, кай җирләрдә амин тот дип әйтәләр. Балачакта аның мәгънәсен белмәсәк тә, дога кылу рәвешен китерә идек, хәзер дә оныкларны өйрәтәбез, бу – шөкернең бер дәрәҗәсе, иң астагысы. Иң бөек дәрәҗә – намазда сәҗдәгә киткән вакытта. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә кабат-кабат намаз укуны әмер итә. Ләкин мөхтәрәм кардәшләр, безнең җәмгыятебездә гыйбадәттә булучылар бик аз. Алда телгә алган спектакльдәге сорауның төп җавабы менә шушында инде.

Узган 20 гасырда адәм балаларына Аллаһы Тәгалә ике афәт, ике дөнья сугышына рөхсәт бирде. 19 гасыр азагы, 20 гасыр башында дөньякүләм кадимчеләр-җәдидчеләр дигән мәгънәви бәрелеш булып узды. Монда җәдидчеләр җиңеп, күп нәрсәне үзгәрттеләр – болар барысы халыкны диннән ерагайту чаралары булды. Хәзер мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукайның күп шигырьләрен тәрҗемәсез укый алмыйбыз. Дини хезмәтләрне уку югалды. Хезмәтләр бар – тел белмибез, хәреф танымыйбыз – диннән ерагаябыз. Бу хәл дөньякүләм булгач, нәтиҗәсе – беренче бөтендөнья сугышы. Намаз ерагайды, Рамазан аенда ураза юк. Шул сәбәпле колларына да беренче афәт җибәрде.

Инде тагын якын тарихыбызга карасак, ни күрәбез? Сабак барып җитмәде. Яңадан динне бетерү юлы көчәйде. Мәчетләр ябылды, манаралар киселде, христианнарның да чиркәүләре шартлатылды, руханиларны, кайсы диндә булуына карамастан, аттылар, сөргеннәрдә череттеләр. Нәрсә булса булсын, халык диннән ерак булсын. “Дин халыкка әфьюн”, дип, хаккый наркотиклар белән халыкны агулау барлыкка килде. Халык диннән ерагайган саен тагын намаз югалды, ураза бетте; мәчет, чиркәүләрне клуб ясап, дөбер-шатыр биедек, мәчетләрдә кино карау һәм хәрам эшләр пәйда булды. Тагын дөньякүләм динне бетерү чәчәк атты. Икенче бөтендөнья сугышы дигән афәт килде.

Хәзерге заманда без нәрсә күзәтәбез? Тагын шул ук тырмага басабыз. Хәзерге вакытта дингә якынаю күренсә дә, тискәре яклар да бик күп шул, еш кына һаман ислам динен начар итеп күрсәтергә тырышалар.

2010 елда Аллаһ безгә бер кисәтеп “бармак” янады дисәк булыр. Корылык булды гел. Чишмәләр кипте, инешләр югалды, басуда игеннәр кибеп бетте, әмма без кисәтүне аңламадык. Инде тәүбә кылыйк, Аллаһтан мондый афәтләр җибәрмәсен өчен гафу үтенеп, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелырга насыйп итсен. Тагын өченче мәртәбә бу сорау яңгырамасын иде.

Тагын да өстәп әйтсәк, Аллаһ бездән барып тайга аударуны, таш ватуны таләп итми. Бары тик биргән нигъмәтләренә шөкер итәргә куша, намаз, ураза, мөмкинлегең-байлыгың булса, хаҗ, нәфес белән сугышу–җиһадны фарыз кыла. Әлбәттә, боларны үтәү өчен Аллаһны танып, чын күңелдән, фикерләп, аңлап, шәһадәт китерергә кирәк. Шул чакта фарызларны үтәү бик җиңел булыр, иншааллаһ.

***Яхъя Хөсәен, Чаллы шәһәре.***
***(Редакциядән: хат кыскартып бирелә)***

---

*Юл язмасы*

# “Дөнья бер алдын, бер артын күрсәтә икән...”

Кайчандыр Михаил Задорнов концертына баргач, урыннарыбыз янәшә туры килгән ир һәм хатын белән шул чагында беркадәр аралашып калган идек. Уртак танышлар барлыгы ачыкланды, юмор, эстрада турында гаплəшеп алдык... Байтак еллар узгач, әле күптән түгел генә Рамил белән очрашырга туры килде. Ул танып эндәшмәсә, бер аягына шактый аксый төшеп атлаган бу ир заты яныннан сүзсез генә узып китәсе идем...

- Ике ел элек авариягә эләктем мин. Рульдә шоферым иде, “КамАЗ” астына барып кердек. Алай бозлавык та түгел иде, белмим инде, очраклы хәл булдымы, берәрсе “булыштымы”... Мин башта дүрт ай буе больницада селкенә дә алмый яттым, сүтеп җыйдылар инде, сүтеп җыйдылар. Врачларның берсе минем хатынга: “Барыбер кеше булмый”, – дип тә әйткән булган. Барысына үч иткәндәй, яшәп ятам әле, менә, ике ел дигәндә кеше рәтенә кереп барам. Болай йөрерлек булгач, сөенеп кенә торырсың. Больницада түшәмгә текәлеп яткан чагында бөтен дөнья чын йөзен күрсәтә икән ул, кемнең кем икәне дә ачыклана. Дус дип йөргәннәр арасында бер генә тапкыр хәл белергә килмәгәннәре дә, бер килеп, минем тере мәет булып ятканны күргәч, бүтән аяк басмаганнары да булды. Элек җыелышларда, банкетларда янда сырышып йөргәннәр дә юкка чыкты. Ну туганнар нык булды! Бер генә минутка да ялгызымны калдырмадылар. Хатын бөтенләй больницада яшәде дисәм дә була. Мин аңга килеп, сөйләшә башлагач, карыйм, үзе елый, үзе шаярта: “Дежур торырга чәчбиләреңнең бер-икесе килмәсме дисәм, чырайларын да күрсәтмиләр”, – ди, елый-көлә. Чәчбиләргә урынга кадакланган чирләшкә кирәкме, аларга акча булсын, күңел ачарга булсын... Һавадан алып әйтүе түгел инде хатынның, гөнаһлар булгалады, нигә яшереп торырга. Озын аяклы берсенә ияреп, өйдән дә чыгып киттем... Сөйләргә яраганы дип... Хәзер искә төшерсәң, диваналыгыма үзем дә шаккатып куям. Шәһәр читендә хан сарае кебек йортым, әле мәктәптә укыган ике балам, курчак кебек хатыным бар. Ә мин шуларны калдырдым да Лиана янына яшәргә күчтем. Аның ике бүлмәле фатиры бар, беләм инде, фатирны да әйбәт кенә урында утыручы бер түрә янында бөтерелеп эләктергән, ресторанда утырганда үзе ычкындырган иде... Чибәрлеге белән алдадымы, үзем дуракмы, кем белсен – шуңа сагыз кебек ябыштым бит. Чибәрлеккә чибәр: Голливуд артисткалары кебек, сап-сары чәч, озын буй, озын ботлар... Һәрчак киенеп-ясанып, үзен карап кына йөри. Ну акыл үзенә кирәк якка гына эшли. Белем дигән нәрсәнең “б” хәрефе дә юк, бер генә темага да сөйләшәм димә. Мәктәптән ничек аттестат алып чыккан бу дип кайчакта шаккатып куя идем, авылына кайткач аңладым. Әти-әнисе янына кайткан идек, бетеп барган бер авыл, йорт-җирләре уртача гына, әти кешенең эчүдән айныганы юк, булган дөньяны әнисе сөйрәп бара икән. Үземне алай кияү дип хис итмәсәм дә, бер файдам тисен дип, лапас буенда өелеп яткан бүкәннәрне ярырга тотындым, шул арада болай, сүз юктан сүз булсын дип кенә “теща” тиешле кешене сөйләндерә башладым: авыл ничек, яшьләр каламы, мәктәп бармы... Кул селтәп зарланырга тотынды бу, Лиананың күрше авылдагы ярдәмче мәктәптә укыганын да әйтеп салды. Төпчек балалары да шул коррекцион мәктәпкә йөри икән. Ата кеше яз-җәй көннәрендә шабашкада йөри, кыш көне эш юк, эчеп ятудан башканы белми. Әни кеше үзе фермада сыер сава, хезмәт хакы алган көнне иренең бурычларын түләп, ике кулын селтәп кала икән. “Кызларыма гел әйтәм, атагыз кебек бетле хәерчегә барып каплана күрмәгез. Унга барыгыз – уңганчы барыгыз, дим. Соң, яшьлекләре бар, чибәрлекләре бар, кадерен белеп калсыннар. Ашыйсын ашап, киясен киеп дигәндәй”... Дөресен әйткәндә, мин үзем дә шулайрак уйлап яшәүче идем бит: гомер бер генә килә, акча бар, мөмкинлек бар, теләгәнчә яшәп калырга кирәк... Ә менә “теща”ның шулай дип көлеп торуы әллә нишләтте дә куйды. Анасының да, кызының да мине савым сыеры урынына гына күрүе түгелме соң?..

Шәһәргә кайтуга, бер-ике көн уйланып йөрдем. Туктале, дим, нәрсәгә мин үземә баш авыртуы эзләп йөрим соң әле? Бүген булмаса иртәгә барыбер юллар аерыласы көн кебек ачык, чөнки мин инде Лианадан туя башлаганымны, алай гына да түгел, хәтта җирәнә башлаганымны аңлаган идем. Шулай-шулай, мин үз йортыма, хатыным янына кайтам дигәч, әйткән сүзе, беләсеңме, нинди булды: “Син миңа бераз акча калдыр инде, әле мин кайчан яңа кавалер табам...”

Хатын өйгә керттеме дисеңме? Беренчедән, өй – минеке, икенчедән, чыгып киткәндә үк ул минем әйләнеп кайтасымны белә иде, беренче тапкыр гына түгел... Аннан, балалар да сагындырды. Кич белән муенга килеп сарылулары үзе бер куаныч. Мырлый башласа, мин хатынга элегрәк гел әйтә идем: мин – ир кеше, әзрәк һава алыштырып кайтуны купайтып утырма. Үзең дә барасы килгән җиреңә бар, минем хатын кеше күзе төшмәслек булырга тиеш түгел бит инде, ди торган идем. Чын инде, чын... Шуңа жене котыра торган иде.

Булды инде, аның нервысында уйнаган чаклар күп булды. Больницада чагында, аңга килүгә, бүтән эш булмагач, уйланудан баш чыкмады. Күземне ачсам да, күземне йомсам да – янәшәмдә хатын утыра, мине кайгырта, мине саклый. Әйттем бит, дус дип йөргәннәрне җил өреп таратты. Бизнесны бертуган энекәшем саклап калды, әле дә ул булды. Мин комада ятканда, кайда, нәрсә булганы турында берни дә белмәдем бит, соңыннан, инде өйгә кайткач кына җайлап-җайлап сөйли башладылар. Ышанычы дус дигән кешенең хатынга “акыллы” киңәшләр бирүен дә – врачлардан мине интегеп ятудан “коткаруны” сорарга кирәк диюен дә ишетеп шаккатмадым, баштагы көннәрдә эштәгеләрнең, чышан-пышан килеп, минем кабинетта актарынуларын белеп тә ул хәтле исем китмәде. Хатынның намазга басуын ишеткәч, күз маңгайга менде менүен. Ничек инде, дим, син бит әле ябь-яшь, әби булгач та җитешер идең әле, дим, үземчә шаяртып... “Син больницага эләккәч, исән калуыңны, терелеп аякка басуыңны сорап, көн саен биш вакыт намазда елый-елый теләк теләдем. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән генә терелдең, ул гына булышты. Врачлар кул селтәгән иде бит”, – диде хатын, минем тозсыз шаяртуыма ачуланып. “Мин булмасам, бер башың тынычлап яшәгән булыр идең әле, нервыңа тиюче дә, елатучы да булмас иде. Бай хатынга свежий ир дә тиз табылыр иде”, – дим, һаман шаяртып. “Балаларның туенда парлап утырасым килә, әле аларны кеше итәсе бар. Ир табылыр ул, ә балаларга әти табылмас”, – диде хатын, мине шап итеп урынга утыртып...

Менә шул. Хәзер тыныч кына яшәп ятабыз. Алай уңга-сулга йөргән дә юк, йөрергә уйлаган да юк. Җомга намазына барыштыра башладым, әле өйрәнеп кенә килү... Дөнья шулай бер алдын, бер артын күрсәтә икән ул, кемнең кем, нәрсәнең нәрсә икәнен дә аңлата, күп нәрсәгә күз ачыла башлый. Тик аңынчы күп вакыт якын кешеләребезнең кадерен белмичә, байтак хаталар эшләп ташлыйбыз...

**Айгөл Әхмәтгалиева.**

# БЕЛӘСЕЗМЕ?

*Ата-ананың баласына карата булган вазыйфалары нигездә түбәндәгеләр:*

*– бала тугач, дини гадәтләр буенча, матур вә мәгънәле исем кушу;*

*– баласын фәкать хәләл ризыклар белән тукландыру;*

*– ир баланы сөннәткә утырту;*

*– бала мәктәп яшенә җиткәч, аны укыта башлау;*

*– 7 яшеннән дини белемнәрне өйрәтү, кыска сүрәләрне ятлаттыру, ун яшеннән намаз укырга кушу. Бу яшьтән соң балага дин нигезләрен һәм Коръән укырга өйрәтү ата-ананың иң мөһим вазыйфаларыннан санала;*

*– балалар арасында аерма ясамау:*

*– баланың яхшы дус табуына игътибар итү;*

*– яше җиткәч, баланы ислам шәригатенә муафыйк рәвештә никахландыру.*

# Кунак ашы – кара-каршы

Беркөн бер авыл карты мөфти-казый әфәндегә килеп, улына шикаять белдерә:

– Мөхтәрәм казыем, кичә мине улым кырда кыйнады, үгезләр куа торган чыбыркысы белән сукты. Җаным бик әрнеде, бик еладым. Мин баламны шуның өчен үстердеммени? Бу картлык хәлемдә мин хәзер ни эшлим инде? Бүген менә сиңа килдем, бер юл күрсәт миңа, бер акыл бир. Мин хәзер ни кылырга да белмим, хуҗам, ялварам сиңа, миңа ярдәмче бул.

Казый әфәнде:

– Сүбехәнәллаһ! Ничек инде бала атасына кул күтәреп сугар?! Әллә син улыңа дин өйрәтмәдеңме? Ата-ана хакының изгелеген улыңа аңлатмадыңмы? Кечкенәдән әхлак, тәрбия үрнәкләре бирмәдеңме?

Карт:

– Хөрмәтле хуҗам! Авыл тормышын беләсең бит, сез әйткәннәрне өйрәтмәдем шул. Авыл җирендә эш күп, кыенлыклар-мәшәкатьләр күп, хайваннар карыйсы, иген үстерәсе, утын әзерлисе... Боларның берсен дә эшләмичә булмый.

Казый күзе яшьле картка:

– Алай булгач инде, бабакай, син улыңны гаепләмә. Ул сине җир сөрә торган үгезләре белән бер саный. Чөнки улың өчен синең белән үгезләр арасында бернинди аерма да юк. Улыңа ата кадерен өйрәтмәгәнсең. Ул үгезләргә сугам дип сиңа суккан. Юкса бала атасына кул күтәрмәс иде... – дип, картның улына карата әтилек вазыйфаларын үтәмәгәнлеген аңлатты.

***Динне белмәгән бала дин гыйлеменнән хәбәрдар булмаган әти-әнисенә игелек күрсәтерме? Юк шул, күрсәтмәс...***

## *Хөрмәтле укучыларыбыз!*

Элек-электән халык телендә мөнәҗәтләр, бәетләр яшәп килә. Мәсәлән, “Менә шундый заман җитәр” дигән мөнәҗәтне төрле якта төрле куплетлар өстәп әйтәләр. Сездә аның тулырак вариантлары табылмасмы? Хәзинәгездә башка мөнәҗәтләр, риваятьләр булмасмы? Газетага юлласагыз, бик шат булыр идек.

## Менә шундый заман җитәр

Дөньяда ямь бетәр шунда –
Халык китәр уңга-сулга.
Изге гамәл гел кылмаслар,
Хәрам мал күп булыр кулда.
Аталарда гайрәт бетәр,
Балаларда шәфкать бетәр,
Туганнарда рәхмәт бетәр –
Менә шундый заман җитәр.
Бик күп биналар салырлар,
Ашыгып анда барырлар,
Эчендә гауга корырлар,
Менә шундый заман җитәр.
Биналары биек булыр,
Эче тулы зиннәт булыр,
Дин дөньясы бозык булыр –
Менә шундый заман җитәр.
Дин гыйлемен бетерерләр,
Фән гыйлемен күтәрерләр,
Шуның белән көн күрерләр –
Менә шундый заман җитәр.
Галимнәре вәгазь сөйләр,
Кайберләре гайбәт сөйләр,
Күп адәмнәр хәвефле үләр,
Менә шундый заман җитәр.
Ир-хатыннар хәмер эчәр,
Төрле уеннар корырлар,
Ислам динен онытырлар,
Менә шундый заман җитәр.
Базарлар кыйммәтләнер,
Яңгырлар сирәк явар,
Хәрам ашау күп булыр –
Менә шундый заман җитәр.
Җаннары һич тыныч булмас,
Тәннәре һич сихәт булмас,
Нидән икәнен белмәсләр –
Менә шундый заман җитәр.
Яхшылыкка юл куймаслар,
Яманлыкка сүз катмаслар,
Хак сүзгә һич ышанмаслар –
Менә шундый заман җитәр.
Дин иясе гаҗиз булыр,
Намазлары зәгыйфь булыр,
Зәкят бурыч булып калыр –
Менә шундый заман җитәр.
Атасыз бала күп булыр,
Маллы кеше саран булыр,
Мәҗлесләрдә уен булыр –
Менә шундый заман җитәр.
Балалары түрә булыр,
Хатыннары солтан булыр,
Хатынга ир кол булыр,
Менә шундый заман җитәр.
Адәмнәрнең өсләрендә
Аллы-гөлле чәчәк булыр,
Берсен салыр, берсен кияр –
Менә шундый заман җитәр.

**Саулыгым – байлыгым**

## Ромашка

Җәй бизәге ромашка дару үләне буларак та бик файдалы. Аның чәчәкләре тир кудыру үзлегенә ия, төнәтмәсен ашказаны-эчәк авыруларыннан, аллергиядән эчәләр.

Ашказаны-эчәк авыруларын, бавыр һәм үт куыгын дәвалау өчен, 1 стакан кайнаган суга 1 аш кашыгы чәчәкләр исәбеннән төнәтмә әзерлиләр, сөзгәч, суытып, көнгә 3-4 тапкыр 1-2 аш кашыгыннан алып 1/3 стаканга кадәр эчәләр. Халык медицинасында ромашка төнәтмәсен еш кына авыртуны басучы һәм тынычландыручы чара буларак та кулланалар. Авыз эченең лайлалы тышчасы ялкынсынганда, ангина вакытында авызны ромашка төнәтмәсе белән чайкарга мөмкин. Бу очракта төнәтмәне 1 стакан суга 20 г чәчәк һәм 4 г бор кислотасы кушып ясыйлар. Күз кабаклары ялкынсынганда, ромашка төнәтмәсе белән иртән һәм кич күзне юу сихәт бирер. Тимрәү, җәрәхәт, тирән яра булганда, рентген нурланышы алганда, ромашка төнәтмәсеннән ванна ясыйлар, бәйләвеч куялар. Бәрелгән-сугылганда, ревматизм



һәм подагра нәтиҗәсендә буыннар авыртканда ромашка белән кайнар компресс кую файдалы. Моның өчен 2-3 аш кашыгы чәчәкне боткасыман масса барлыкка килгәнче пешерәләр, аны кайнар килеш чиста тукымага салалар да авырткан урынга каплыйлар.

1,5 л суга 4 аш кашыгы ромашка чәчәге салып кайнаткач, аның белән чәчне юарга мөмкин. Чәч ялтырап, шома, матур булып калыр.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.
**Тиражы 1280.**

**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**26 июль 16 сәг.**
**фактта 26 июль 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**